

Зульфия Камиль кызы Алтаеваны кадошкинолылар, гомумән, Кадошкино районы хакимиятенен муниципаль архивы модире буларак беләләр. Әмма Зульфия Камилевна бу вазыйфада һәрвакытта да эшләмәгән. Һонәре буенча ул педагог, М.Е.Евсевьев исемендәге МГПИнын физика-математика факультетын тәмамлаган. Ун елдан артык районындагы Высокое авыл мәктәбендә профильле фәннәрне унышлы алып барган.
- Укытучы булу минем балачак хыялым иде, - дип искә ала Зульфия Камиль кызы. - Яшь чагындагы хыялымны тормышка ашырыр очен прединститутка керергә кирәк иде. Мәктәптә тогәл фәннәрне бик ярата идем, шуна кvрә мин математик булырга теләдем.
  Зульфия мәктәптә яхшы укый; аны комеш медаль белән тәмамлый. Бер генә имтихан тапшырып, институтка укырга керә. Студент тормышы аны vз эченә тиз чолгап ала; торле чараларда бик актив катнаша. Һәм 1992 елда яшь укытучы буларак мәктәпкә килгәч тә, Зульфия Камиль кызына студент еллары тәжрибәсе бик тә кирәк булып чыга.

- Беренче коллектив һәрвакыт истә озакка кала, - дип сvзен дәвам итә ул. - Практикамны Высокое мәктәбендә vткән идем, шуна коллектив таныш иде һәм бик тиз иялəштем. Авырлык-лар да, ерак авыл юлы да куркытмады мине; сәләтле балалар белән эшләргә теләгем зур булды. Мәктәп таркалганчы физика һәм математика дәресләрен алып бардым. Шулай ун ел педагогик хезмәтемнен vтеп киткәнен сизми дә калдым. Мәктәп таркалгач, 2004 елда архивка эшкә урнаштым. Бу минем яна эшем кvнелемә хуш килде, мине кызыксындырды. Могаен, архив эшендә vземне таптым дип әйтергә хакым бар. Һәм башка эшләр эзләргә теләгем дә юк.
Чыннан да, Зульфия Камилевна бу олкәдә vзен тапкан. Тырыш хезмәте, торле һонәри осталык бәйгеләрендә актив катнашуы очен Рәхмәт һәм Мактау грамоталары белән бvләкләнде. Шул исәптән 2014 елда алынган Федераль архив хезмәте житәкчесенен шәхси Рәхмәте дә бу рәтне бизи. Ул 2016 елда «Ин яхшы архивчы» һонәри осталык конкурсында да жинә. Һәм менә яна танылу - 2017 елда муниципаль учреждение «ин яхшы муниципаль архив» номинациясендәге һонәри конкурста икенче урынны ала. Бу модирнен оештыру осталыгына һәм архивтагы эшенә югары бәя дигән сvз. Бvген дә торле конкурсларда катнашып, яратып эшли.
Зульфия Алтаеваны район мәктәп-ләрендә дә кvрергә була. Ул vз эше буенча ботен

кеше белән хезмәттәшлек итә. Хәтта мәктәпләрдә архив дәрес-ләре, Россия, республика, районнын тарихи даталары буенча чаралар vткәрә. Жинv Коненә һәм район Коненә кvргәзмәләр оештыра. Бик кvп материал тупланган архивта, шул материалларны ойрәнә, халыкка житкерә. Мәсәлән, Россия архив хезмәтенен 100 еллыгына З.К.Алтаева vз эше, архив эше турында документаль фильм булдырган. Аны кvп кенә коллективлар, шул исәптән мәктәпләрдә дә карыйлар. Аны район хакимияте сайтында карарга була. Чыннан да, фильм бай. Ул район тарихын эшләvче кешеләр турында.
Матур яши Зульфия Камиль кызы. Унышлы хезмәткәр булуы белән бергә, ул - чангы ярышында беренче, йогерv юлында да кондәшләреннән калышмый. Спорт чараларында гына тvгел, районда узучы мәдәни-массакvләм чараларда да һәрчак катнаша һәм оештырырга ярдәм итә. Ансамбльдә жырлый. Районы очен ихластан тырыша. Патриотлык рухы кочле анын. Зульфия Камилевна Латыш авылында яши, район vзәгендә эшли. Татар жанлы кеше ул. Авылы ана чыннан да кыйммәт. Анда - туган йорты да, соекле әнисе дә. Тагы ул аш-суга оста, менә дигән кулинар һәм хужабикә дә - бәлешләрне, пәрәмәчләрне яратып пешерә. Улы жиденче сыйныф укучысы, искиткеч, бик кызыклы малай. Әнисе кебек vк бик яхшы спортчы!
Йомгаклап болай әйтәсе килә: унган кеше торле яктан унган  - эшен дә, тормышны да яратып яши белә.

**Н.Хәлил**